КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2021 ел, 27 гыйнвар | г.Казань | № 28

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 ел, 30 сентябрь, 887 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 ел, 30 сентябрь, 887 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 декабрь, 1159 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2021 елга социаль-көнкүреш хезмәтләре, социаль-медицина хезмәтләре, социаль-психологик хезмәтләр, социаль-педагогик хезмәтләр, социаль-хезмәт хезмәтләре, социаль-хокукый хезмәтләр, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларындагы хезмәтләр күрсәтүне кертеп, стационар формада социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарда:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «4. | Балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләре | 1641,21 | - |
| 4.1. | социаль-көнкүреш хезмәтләре | 424,20 | - |
| 4.2. | социаль-медицина хезмәтләре | 180,07 | - |
| 4.3. | социаль-психологик хезмәтләр | 49,85 | - |
| 4.4. | социаль-педагогик хезмәтләр | 788,92 | - |
| 4.5. | социаль-хезмәт хезмәтләре | 88,48 | - |
| 4.6. | социаль-хокукый хезмәтләр | 109,69 | -»; |

II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «4. | Балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләре | 139,74 | 96,58 | 43,16»; |

әлеге карар белән расланган 2021 елга социаль-көнкүреш хезмәтләре, социаль-медицина хезмәтләре, социаль-психологик хезмәтләр, социаль-педагогик хезмәтләр, социаль-хезмәт хезмәтләре, социаль-хокукый хезмәтләр, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларындагы хезмәтләр, ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтүне кертеп, стационар һәм ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарда:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «5. | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең көндезге эш бүлекләре | - | - | 483,27 | 506,61 |
| 5.1. | социаль-көнкүреш хезмәтләре | - | - | 17,41 | 17,41 |
| 5.2. | социаль-медицина хезмәтләре | - | - | 80,33 | 84,07 |
| 5.3. | социаль-психологик хезмәтләр | - | - | 25,94 | 25,94 |
| 5.4. | социаль-педагогик хезмәтләр | - | - | 210,78 | 223,85 |
| 5.5. | социаль-хокукый хезмәтләр | - | - | 8,65 | 8,65 |
| 5.6. | социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларында күрсәтелә торган хезмәтләр | - | - | 140,16 | 146,69»; |

II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «5. | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең көндезге эш бүлекләре | 127,95 | 84,37 | 43,58»; |

әлеге карар белән расланган 2021 елга дәүләт хезмәте күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларына түбәндәге эчтәлекле 8 һәм 9 пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «8. | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең көндезге эш бүлекләре | |
| 8.1. | «Казан шәһәре» шәһәр округындагы халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең көндезге эш бүлеге | 1,37 |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | Балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләре | |
| 9.1. | «Дуслык» девиант тәртипле балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль-тернәкләндерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе | 1,00»; |

әлеге карар белән расланган 2021 елга стационар һәм ярымстационар формалы социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмаларында койка-көннәр һәм койка-урыннар санының «Казан шәһәре» юлына түбәндәге эчтәлекле асъюл өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» шәһәр округындагы халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең көндезге эш бүлеге | - | 14 760 | - | - | 60 | -»; |

әлеге карар белән расланган 2021 елга Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестрына кертелгән, әмма социаль хезмәтләр күрсәтү белән бәйле дәүләт заказын үтәүдә катнашмаучы дәүләтнеке булмаган оешмаларга компенсация түләүгә (чыгымнарны каплауга) Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча күләмен билгеләү өчен кеше, койка-көннәр санының «Казан шәһәре» юлына түбәндәге эчтәлекле асъюл өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Дуслык» девиант тәртипле балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль-тернәкләндерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе | социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен социаль хезмәтләр | - | 3 650 | - | -». |

2. Бу карарның гамәле 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин